Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче Кече Аксубай авылында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 27 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлегенең Кече Аксубай торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Кече Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, гражданнар өчен 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- су белән тәэмин итү өчен тирәнгә куела торган насос сатып алу;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау

3. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubaevo.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Аксубай
авыл җирлеге башлыгы М. М. Сөләйманкин